**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О государственном заказе на мероприятия по профессиональному развитию государственных гражданских служащих Республики Татарстан**

В соответствии с Федеральным законом от 27 июля 2004 года № 79-ФЗ «О государственной гражданской службе Российской Федерации», Указом Президента Российской Федерации от 21 февраля 2019 года № 68 «О профессиональном развитии государственных гражданских служащих Российской Федерации» и Законом Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» **постановляю**:

1. Утвердить прилагаемое Положение о государственном заказе на мероприятия по профессиональному развитию государственных гражданских служащих Республики Татарстан.

2. Внести в Положение о Департаменте государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 22 декабря 2005 года № УП-512 «О Департаменте государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 26 июля 2013 года № УП-693, от 28 февраля 2014 года № УП-233 и от 20 августа 2014 года № УП-797), следующие изменения:

а) в абзаце восьмом пункта 6 слово «дополнительного» исключить;

б) в пункте 7:

абзац второй дополнить словами «, в том числе проектов государственных программ Республики Татарстан»;

абзац третий признать утратившим силу;

абзац тридцать седьмой признать утратившим силу;

в абзаце тридцать восьмом слово «переподготовки» заменить словами «профессиональной переподготовки»;

в абзаце тридцать девятом слово «учреждений» заменить словом «организаций»;

абзац сороковой изложить в следующей редакции:

«формирование государственного заказа на мероприятия по профессиональному развитию государственных служащих»;

в) в абзаце шестнадцатом пункта 8 слова «профессиональной переподготовки и повышения квалификации» заменить словами «профессионального развития»;

г) в абзаце шестом пункта 9 слово «учреждения» заменить словом «организации»;

д) в пункте 11 слова «Советом муниципальных образований Республики Татарстан» заменить словами «Ассоциацией «Совет муниципальных образований Республики Татарстан»;

е) в абзаце восьмом пункта 14 слова «направлении на обучение и повышение квалификации» заменить словами «организации профессионального развития».

3. Кабинету Министров Республики Татарстан:

утверждать по согласованию с Президентом Республики Татарстан государственный заказ на мероприятия по профессиональному развитию государственных гражданских служащих Республики Татарстан в пределах средств, предусмотренных в бюджете Республики Татарстан на соответствующий год;

привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию.

4. Департаменту государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан ежегодно, не позднее 30 ноября, представлять на утверждение в Кабинет Министров Республики Татарстан проект государственного заказа на мероприятия по профессиональному развитию государственных гражданских служащих Республики Татарстан.

5. Руководителям государственных органов Республики Татарстан обеспечить:

ежегодное, не позднее 1 октября, представление в Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан заявок государственных органов Республики Татарстан на реализацию мероприятий по профессиональному развитию государственных гражданских служащих Республики Татарстан на соответствующий год посредством государственной информационной системы Республики Татарстан «Единая информационная система кадрового состава государственной гражданской службы Республики Татарстан и муниципальной службы в Республике Татарстан»;

создание необходимых условий для освоения государственными гражданскими служащими Республики Татарстан образовательных программ дополнительного профессионального образования и реализации иных мероприятий по профессиональному развитию государственных гражданских служащих Республики Татарстан.

6. Финансирование расходов, связанных с реализацией настоящего Указа, осуществлять за счет средств бюджета Республики Татарстан на соответствующий финансовый год и плановый период, предусмотренных на выполнение государственной программы Республики Татарстан развития государственной гражданской службы Республики Татарстан.

7. Признать утратившими силу:

Указ Президента Республики Татарстан от 22 ноября 2008 года № УП-599 «О государственном заказе на дополнительное профессиональное образование государственных гражданских служащих Республики Татарстан»;

пункт 1 Указа Президента Республики Татарстан от 20 марта 2013 года № УП-240 «О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан и признании утратившими силу отдельных указов Президента Республики Татарстан»;

пункт 4 Указа Президента Республики Татарстан от 12 июня 2014 года № УП-569 «О Совете по вопросам кадровой политики при Президенте Республики Татарстан»;

Указ Президента Республики Татарстан от 12 февраля 2016 года № УП-137 «О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О государственном заказе на профессиональную переподготовку, повышение квалификации и стажировку государственных гражданских служащих Республики Татарстан».

8. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
24 апреля 2020 года
№ УП-252

Утверждено
Указом Президента
Республики Татарстан

от «24» апреля 2020 года

№ УП-252

**Положение**
**о государственном заказе на мероприятия по профессиональному развитию государственных гражданских служащих Республики Татарстан**

1. Настоящее Положение определяет порядок утверждения, финансирования и исполнения государственного заказа на мероприятия по профессиональному развитию государственных гражданских служащих Республики Татарстан (далее – государственный заказ, гражданские служащие), а также полномочия государственных органов Республики Татарстан по размещению государственного заказа.

2. Государственный заказ включает в себя:

а) государственный заказ на дополнительное профессиональное образование гражданских служащих;

б) государственный заказ на иные мероприятия по профессиональному развитию гражданских служащих.

3. Подразделение государственного органа Республики Татарстан по вопросам государственной службы и кадров ежегодно формирует заявку государственного органа Республики Татарстан на реализацию мероприятий по профессиональному развитию гражданских служащих на очередной год (далее – заявка).

Заявка формируется в государственной информационной системе Республики Татарстан «Единая информационная система кадрового состава государственной гражданской службы Республики Татарстан и муниципальной службы в Республике Татарстан» (далее – Информационная система).

4. Объем финансирования расходов по государственному заказу определяется в соответствии с экономическими нормативами стоимости услуг по реализации мероприятий по профессиональному развитию гражданских служащих, утверждаемыми Кабинетом Министров Республики Татарстан.

5. Заявка должна быть сформирована государственными органами Республики Татарстан в Информационной системе в срок не позднее 1 октября года, предшествующего планируемому.

6. На основе поступивших заявок государственных органов Республики Татарстан Департамент государственной службы и кадров при Президенте

Республики Татарстан готовит проект государственного заказа по форме согласно приложению, определяет его структуру и рассчитывает общий (примерный) объем финансирования на очередной финансовый год и плановый период расходов, необходимых для исполнения государственного заказа.

Подготовленный проект государственного заказа Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан представляет на утверждение в Кабинет Министров Республики Татарстан не позднее 30 ноября года, предшествующего планируемому.

Кабинет Министров Республики Татарстан по согласованию с Президентом Республики Татарстан после принятия закона Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на соответствующий год и плановый период утверждает государственный заказ.

7. Государственный заказ содержит сведения:

а) о количестве гражданских служащих, направляемых для получения дополнительного профессионального образования, в том числе по программам повышения квалификации и профессиональной переподготовки;

б) об объеме бюджетных ассигнований, предусмотренных в бюджете Республики Татарстан на дополнительное профессиональное образование гражданских служащих, в том числе на программы повышения квалификации и профессиональной переподготовки;

в) о количестве гражданских служащих, направляемых на иные мероприятия по профессиональному развитию;

г) об объеме бюджетных ассигнований, предусмотренных в бюджете Республики Татарстан на иные мероприятия по профессиональному развитию гражданских служащих;

д) об общем объеме средств на реализацию государственного заказа на мероприятия по профессиональному развитию гражданских служащих.

8. Закупки услуг по профессиональному развитию гражданских служащих осуществляются государственными органами Республики Татарстан с участием Департамента государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан, а в случае размещения по решению Кабинета Министров Республики Татарстан централизованного заказа – Министерством образования и науки Республики Татарстан с участием Департамента государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан в организациях, осуществляющих образовательную деятельность по дополнительным профессиональным программам и (или) проведение иных мероприятий по профессиональному развитию гражданских служащих, в порядке, установленном законодательством Российской Федерации о контрактной системе в сфере закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд.

9. Государственный орган Республики Татарстан (заказчик) совместно с Департаментом государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан с одной стороны и организация, осуществляющая образовательную деятельность по дополнительным профессиональным

программам и (или) проведение иных мероприятий по профессиональному развитию гражданских служащих, определенная в соответствии с законодательством Российской Федерации о контрактной системе в сфере закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд (исполнитель), с другой стороны заключают государственный контракт на проведение мероприятий по профессиональному развитию гражданских служащих.

10. Финансирование государственного заказа осуществляется за счет и в пределах бюджетных ассигнований, предусмотренных в бюджете Республики Татарстан на соответствующий финансовый год и плановый период на реализацию государственной программы Республики Татарстан развития государственной гражданской службы Республики Татарстан.

11. Государственный заказ может уточняться Кабинетом Министров Республики Татарстан по согласованию с Президентом Республики Татарстан на основании предложений, подготовленных Департаментом государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан.

12. Увольнение с государственной гражданской службы Республики Татарстан является основанием для прекращения финансирования мероприятий по профессиональному развитию гражданского служащего за счет средств бюджета Республики Татарстан.

13. Отчет о выполнении государственного заказа на мероприятия по профессиональному развитию гражданских служащих в разрезе органов формируется в Информационной системе ежегодно.

14. Контроль за ходом исполнения государственного заказа осуществляется Департаментом государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан.

15. Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан ежегодно представляет в федеральный орган исполнительной власти, осуществляющий функции по выработке и реализации государственной политики и нормативно-правовому регулированию в сфере государственной гражданской службы, сведения о реализации государственного заказа.

Приложение
к Положению о государственном
заказе на мероприятия по
профессиональному развитию
государственных гражданских
служащих Республики Татарстан

Форма

**Государственный заказ**
**на мероприятия по профессиональному развитию государственных гражданских служащих Республики Татарстан**
**на ________ год**

1. Государственный заказ на дополнительное профессиональное образование государственных гражданских служащих Республики Татарстан

| Наименование государственного органа | Количество государственных гражданских служащих Республики Татарстан, направляемых для получения дополнительного профессионального образования (человек) | | | Объем бюджетных ассигнований, предусмотренных в бюджете Республики Татарстан (тыс. рублей) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | всего | в том числе по программам | | всего | в том числе на программы | |
| | | повышения квалификации | профессиональной переподготовки | | повышения квалификации | профессиональной переподготовки |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

2. Государственный заказ на иные мероприятия по профессиональному развитию государственных гражданских служащих Республики Татарстан

| Наименование государственного органа | Количество государственных гражданских служащих Республики Татарстан, направляемых на иные мероприятия по профессиональному развитию (человек) | Объем бюджетных ассигнований, предусмотренных в бюджете Республики Татарстан (тыс. рублей) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

3. Общий объем средств на реализацию государственного заказа на мероприятия по профессиональному развитию государственных гражданских служащих Республики Татарстан.

| | |
|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларга дәүләт заказы турында**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү турында» 2019 елның 21 февралендәге 68 номерлы Указы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Кушымтада бирелүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларга дәүләт заказы турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында» 2005 елның 22 декабрендәге ПУ-512 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы, 2014 елның 28 февралендәге ПУ-233 номерлы һәм 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 6 пунктның сигезенче абзацында «өстәмә» сүзен төшереп калдырырга;

б) 7 пунктта:

икенче абзацта «, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектлары» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

утыз җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

утыз сигезенче абзацта «яңадан әзерләү» сүзләрен «һөнәри яктан яңадан әзерләү» сүзләренә алмаштырырга;

утыз тугызынчы абзацта «учреждениеләрнең» сүзен «оешмаларның» сүзенә алмаштырырга;

кырыгынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларга дәүләт заказын формалаштыру»;

в) 8 пунктның уналтынчы абзацында «һөнәри яктан яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү» сүзләрен «һөнәри яктан үстерү» сүзләренә алмаштырырга;

г) 9 пунктның алтынчы абзацында «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алмаштырырга;

д) 11 пунктта «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

е) 14 пунктның сигезенче абзацында «укытуга һәм квалификация күтәрүгә җибәргәндә» сүзләрен «һөнәри яктан үстерүне оештыру турында» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларга дәүләт заказын, Татарстан Республикасы Президенты белән килештереп, тиешле елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча кысаларында расларга;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аның үтәлешен тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

4. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәр ел саен, 30 ноябрьдән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларга дәүләт заказы проектын раслауга кертергә.

5. Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

һәр ел саен, 1 октябрьдән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы аша Татарстан Республикасы дәүләт органнарының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларны гамәлгә ашыруга тиешле елга гаризаларын бирүне;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф программаларын үзләштерү һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча башка чараларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар булдыруны.

6. Әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына

һәм план чорына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын үтәүгә каралган акча хисабына башкарырга.

7. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын үткәрүгә дәүләт заказы турында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-599 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларының үз көчләрен югалтуларын тану турында» 2013 елның 20 мартындагы ПУ-240 номерлы Указының 1 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында» 2014 елның 12 июнендәге ПУ-569 номерлы Указының 4 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын үткәрүгә дәүләт заказы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 12 февралендәге ПУ-137 номерлы Указы.

8. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 24 апрель
№ ПУ-252

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның « 24 » апрелендәге
ПУ- 252 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларга дәүләт заказы турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларга дәүләт заказын (алга таба – дәүләт заказы, граждан хезмәткәрләре) раслау, финанслау һәм үтәү тәртибен, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт органнарының дәүләт заказын урнаштыру буенча вәкаләтләрен билгели.

2. Дәүләт заказы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

а) граждан хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт заказын;

б) граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча башка чараларга дәүләт заказын.

3. Татарстан Республикасы дәүләт органының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе һәр ел саен киләсе елга Татарстан Республикасы дәүләт органы граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларны гамәлгә ашыруга гаризасын (алга таба – гариза) формалаштыра.

Гариза «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Мәгълүмат системасы) формалаштырыла.

4. Дәүләт заказы белән бәйле чыгымнарны финанслауның күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланучы граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларны гамәлгә ашыру буенча хезмәтләргә бәянең икътисадый нормативлары нигезендә билгеләнә.

5. Гариза Татарстан Республикасы дәүләт органнары тарафыннан Мәгълүмат системасында план елыннан алда килүче елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча формалаштырылырга тиеш.

6. Татарстан Республикасы дәүләт органнарыннан килгән гаризалар нигезендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты кушымта нигезендәге форма буенча дәүләт заказы проекты әзерли, аның структурасын билгели һәм киләсе финанс елына дәүләт заказын үтәү өчен кирәкле гомуми финанслау күләмен (чагыштырмача) һәм план чорына чыгымнарны исәпли.

Дәүләт заказы буенча әзерләнгән проектны Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты план елыннан алда килүче елның 30 ноябреннән до соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карап тикшерүгә кертә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Президенты белән килештереп, тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы кабул ителгәннән соң дәүләт заказын раслый.

7. Дәүләт заказы түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

а) өстәмә һөнәри белем алуга, шул исәптән квалификацияләрен күтәрү һәм һөнәри яктан яңадан әзерләү программалары буенча җибәрелүче граждан хезмәткәрләре саны турында;

б) граждан хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүгә, шул исәптән квалификацияләрен күтәрү һәм һөнәри яктан яңадан әзерләү программаларына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме турында;

в) һөнәри яктан үстерү буенча башка чараларга җибәрелүче граждан хезмәткәрләре саны турында;

г) граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча башка чараларга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме турында;

д) граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларга дәүләт заказын үтәүгә гомуми финанслар күләме турында.

8. Граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча хезмәтләр Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты катнашында Татарстан Республикасы дәүләт органнары тарафыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән үзәкләштерелгән заказ бирелгән очракта – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты катнашында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге алып баручы һәм (яисә) дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча башка чараларны уздыручы оешмалардан сатып алына.

9. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты белән берлектә Татарстан Республикасы дәүләт органы (заказчы) бер яктан һәм өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге алып баручы һәм (яисә) дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча башка чараларны уздыручы оешма (башкаручы),

икенче яктан, граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чаралар уздыруга дәүләт контракты төзи.

10. Дәүләт заказын финанслау Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен каралган бюджет ассигнованиеләре хисабына һәм аның чикләрендә тормышка ашырыла.

11. Дәүләт заказына Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан әзерләнгән тәкъдимнәр нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты белән килештереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

12. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасыннан азат ителү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан граждан хезмәткәрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларны финанслауны туктату өчен нигез булып тора.

13. Барлык органнар буенча граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларга дәүләт заказы үтәлеше турында хисап һәр ел саен Мәгълүмат системасында формалаштырыла.

14. Дәүләт заказы үтәлешенең барышын контрольдә тоту Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан тормышка ашырыла.

15. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты дәүләт граждан хезмәте өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органына һәр ел саен дәүләт заказы үтәлеше турында мәгълүмат бирә.

Татарстан Республикасы дәүләт
граждан хезмәткәрләрен һөнәри
яктан үстерү буенча чараларга
дәүләт заказы турында
нигезләмәгә
кушымта

Форма

________ елга

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларга дәүләт заказы**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт заказы

| Дәүләт органы атамасы | Өстәмә һөнәри белем алуга җибәрелүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре саны (кеше) | | | Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме (мең сумнарда) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | шул исәптән түбәндәге программалар буенча | | барлыгы | шул исәптән түбәндәге программаларга | |
| | | квалификацияне күтәрү | һөнәри яктан яңадан әзерләү | | квалификацияне күтәрү | һөнәри яктан яңадан әзерләү |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча башка чараларга дәүләт заказы

| Дәүләт органы атамасы | Һөнәри яктан үстерү буенча башка чараларга җибәрелүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре саны (кеше) | Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме (мең сумнарда) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларга дәүләт заказын үтәүгә бүлеп бирелгән акчаның гомуми күләме.